Безнен регионда житэкчелек, жэмэгать оешмалары тарафыннан балалар мэнфэгатьлэренэ зур игътибар бирелэ. Кадошкино районы муниципаль берэмлегенен депутаты ярдэмендэ Насакан Потьма авылы балаларына шугалак-горки бvлэк йозеннэн урнаштырган.
Эш шунда ки, даими рэвештэ 20 кеше яшэгэн Кадошкино районы Насакан Потьма авылына, жэй каникулларында кунаклар бигрэк кvп жыела. Алар арасында балалар кvбрэк. Балалар – безнен килэчэгебез, игелек-ле эшлэребезне дэвам итvчелэр. Без аларнын балачагы бэхетле булсын һэм алар сэламэт, нык vссен очен барысын да эшлэргэ тиеш.

Жэйге ялларда уен мэйданчыклары балаларнын физик, социаль һэм танып белv vсеше очен бик тэ кирэк. Шулай, авыл активистлары коче белэн, килэчэк буын вэкиллэре ялларын матур vткэрсеннэр очен, ике ел элек иске кибет алды территориясендэ уен мэйданчыгы очен урын чистарталар. Агишев Рустам ярдэме белэн сэленчек-качельлэр, карусель, атылгыч ясап урнаштыралар. Балаларга таучык-горки да булдырырга телилэр, эмма 20 кешенен кvбесе пенсия яшендэ, акчалары артып тормый. Авыл балаларына шатлык бvлэк итэргэ тели авыл халкы. Максатларын тормышка ашыру очен, Асаинов Рашид, Невлютова Антонина Мордовия Дэvлэт Жыелышы депутаты Александр Александрович Болдыревка «Бердэм Россия» жирле ижтимагый партия кабул итv конендэ приемга баралар. Депутат башта мэйданчык чынлап та эшлэвенэ инана һэм сайлаучыларынын наказларын тормышка ашырып, горки жибэрэ һэм эшчелэре аны урнаштыра да. Менэ шул вакыт балаларнын шатлыгын кvрсэ идегез!..